СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 3-32 от « 03 » июля 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»3-25 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 290 нчы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»3-25 нче карарына (29.06.2018ел, 4-27 номерлы, 10.09. 2020 ел, 4-40 номерлы, 15.12.2021 ел, 3-10 номерлы, 09.11.2022 ел, 3-17 номерлы, 14.12.2022ел, 3-18 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «12 688» саннарын «13 323» санына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру

нормативларында:

7 пунктта «17,03» саннарын «21,74» санына, «16,83» санын - «21,51» санына, «13,27» санын - «17,40» санына, «11,34» санын - «15,24» санына, «10,36» санын - «14,12» санына, «9,26» санын- «12,86» санына, «10,69» санын - «14,5» санына, «9,18» санын - «12,77» санына алмаштытырга;

10 пунктның 5 пунктчасында «18 процент» сүзен «41 процентка» сүзенә алмаштырырга;

12 пунктның 6 пунктчасында «18 процент» сүзен «41 процентка» сүзенә алмаштырырга;

Әлеге карарга № 5 һәм № 6 кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлеп килә).

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет, икътисадый сәясәт һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы урынбасары Р.Р.Сәмигуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 апрель, 182 нче
карарына 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының 03 07
2024 ел № 3-32
карары редакциясендә)

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге контрольисәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

(

| Вазифа исеме | Беренче төркем* | Икенче төркем* | Өченче төркем* | Дүртенче төркем* | Сигезенче төркем* |
|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 48 596 | 44 041 | 40 515 | 37 037 | 35 272 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 43 736 | 39 637 | 36 462 | 33 331 | 31 745 |
| Депутат | 21 966 | 21 018 | 19 795 | 17 950 | 17 297 |
| Җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасы | 18 668 | 17 867 | 16 820 | 15 256 | 14 697 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 43 736 | 39 637 | 36 462 | 33 331 | 31 745 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 41 032 | 36 770 | 32 774 | 29 976 | 28 511 |
| Контроль-хисап органы аудиторы | 33 041 | 29 444 | 27 444 | 24 248 | 24 248 |

* Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»3-25 нче карары белән расланган муниципаль берәмлек үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең,

аудиторларының муниципаль хезмәткәрләрен хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыруның 1 пункты нигезендә хезмәт өчен түләү төркеме керә,

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 апрель, 182 нче
карарына 6 нчы кушымта
(Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының 03 07
2024 ел № 3-32
карары редакциясендә)

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләрендә җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазифаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазифа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | республика һәм район әһәмиятендәге шәһәрләр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләрендә | | | | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләрендә һәм шәһәр җирлекләрендә | | | |
| | Дүртенче төркем * | Бишенче төркем * | Алтынчы төркем * | Җиденче төркем * | Тугызынчы төркем * | Унынчы төркем * | Унберенче төркем * | Уникенче төркем * |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 37 037 | 33 608 | 31 634 | 28 250 | 24 789 | 21 723 | 19 991 | 18 260 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 33 329 | 30 246 | 28 465 | 25 263 | 19 770 | 16 185 | 14 366 | 13 324 |
| Депутат | 17 950 | 16 104 | 15 024 | 14 308 | 13 323 | 13 323 | 13 323 | 13 323 |
| Җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасы | 15 256 | 13 688 | 13 323 | 13 323 | 13 323 | 13 323 | 13 323 | 13 323 |

* Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»3-25 нче карары белән расланган муниципаль берәмлек үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының муниципаль хезмәткәрләрен хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыруның 1 пункты нигезендә хезмәт өчен түләү төркеме керә,